Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлегенең Шеңшеңәр торак пунктында
ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2021 елның 17 нче декабре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлегенең Шеңшеңәр торак пунктында халык җыены карар бирде:

1. 50% күләмендә ташлама билгеләнгән I группа инвалидлар, торып укучы студентлар, ялгыз яшәүче өлкән кешеләр, балигъ булмаган балалар тәрбияләүче тулы булмаган гаиләләрдән тыш, Шеңшеңәр авыл җирлегенең Шеңшеңәр авылында яшәү урыны буенча теркәлгән , балигъ булган һәр гражданга 2022 нче елда үзарасалымны 500 сум күләмендә кертергә.

2.Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирлектә әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Г.Тукай урамы буенча җәяүлеләр тротуарын урнаштыру;
- Г. Тукай урамы буенча янгынга каршы гидрант һәм аңа комплектлаучы җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру .

3. Халык җыены нәтиҗәләрен Шеңшеңәр авыл җирлеге Советының мәгълүмәти стендларында урнаштырырга, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында,Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Балтач муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет Рәисе Р.Х.Салихҗанов